РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«30» декабря 2020г. № 1-10

ТР Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ТР Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пункт:

3 пунктның 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән, гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган белешмә (булган очракта);»;

4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан көненнән закон көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Ахметзянов